# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасында юллар фонды турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

1 статья. «Татарстан Республикасында юллар фонды турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992 ел, № 3; 1993 ел, № 3; 1994 ел, № 1-2; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995 ел, № 7-8; 1995 ел, № 9; 1996 ел, № 7; 1997 ел № 7; 1999 ел № 3 ) түбәндәге үзгәрешне кертергә;

5 статьяның 3 пунктындагы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«инвалидларның Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте, Бөтенроссия чукраклар җәмгыяте һәм Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең республика, район һәм шәһәр иҗтимагый оешмалары; алар тарафыннан төзелгән һәм устав капиталлары тулысынча инвалидларның әлеге иҗтимагый оешмалары кертемнәреннән торган һәм гомуми хезмәткәрләр санының кимендә 50 процентын инвалид хезмәткәрләр тәшкил иткән, табышлары тулысынча устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга юнәлдерелүче хуҗалык җәмгыятьләре һәм башка хуҗалык оешмалары».

2 статья. Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 6 декабре
№ 2485